ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**БОЕРЫК**

29.04.2020 № 85-од

Казан шәһәре

Чараларның аерым этапларын үткәрүнең элек чыгарылган боерыкларда билгеләнгән срокларын күчерү турында

Барлыкка килгән вәзгыятьне һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны кисәтү чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары белән кертелгән чикләү чаралары комплексын исәпкә алып,

боерык бирәм:

1. Чараларның түбәндәге аерым этапларын үткәрүнең элек чыгарылган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыкларында билгеләнгән срокларын Татарстан Республикасы территориясендә санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр күчерергә:

- Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә бәйрәме уздыру турында» 2019 елның 21 октябрендәге 190-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи - Тарихта без эзлебез» ел саен үткәрелә торган шәҗәрә бәйрәмен уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 гыйнварындагы 16-од номерлы боерыгы белән гамәлгә куелган бәйрәмнең зона һәм республика этапларын;

- Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Минем нәселем» республика генеологик тикшеренүләр конкурсы турында» 2020 елның 27 гыйнварындагы 17-од номерлы боерыгы белән гамәлгә куелган конкурсның республика этабын;

- Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларының грант ярдәме

алуга конкурсы турында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 20-од номерлы боерыгы белән расланган конкурс проектларын Грантка дәгъва кылучылар тарафыннан гавами яклау этабын.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам

Рәис Г.З. Габдрахманова